Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
Иске Михайловка гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

8 декабрь 2023 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023елның 08декабрендә18сәгать 00 минутта булганграждannarның җыен нәтиҗәләре нигезендәтүбәндәге «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге Иске Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Ирекле авылындагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл территориясен капиталь ремонтлау һәм төзекләндерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 157 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 83 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 71«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 12 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге Иске Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннантыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Ирекле авылындагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл территориясен капиталь ремонтлау һәм төзекләндерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?»турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Михайловка авылы, Школьнаяурам, 43 йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорт,территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул

ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин